КИЛЕШЕНДЕ:
МБГББУ «29нчы гимназия»
директоры
_________________ А.Г. Мәхмутов

РАСЛЫЙМ:
Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе башлыгы
_________________ В.Х. Харисов

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның
төбәкара конференциясен үткәрү турында
**НИГЕЗНАМӘ**

## I. Гомуми мәгълүмат

Төбәкара фәнни-гамәли конференция Татарстан Дәүләт Советы депутаты, РСФСРның К.С.Станиславский исемендәге һәм ТАССРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты Туфан Миңнуллинның иҗади мирасын өйрәнү, пропагандалау, 2014-2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан үткәрелә.

**Катнашучылар:**

Туфан Миңнуллин иҗатын өйрәнү, барлау һәм пропагандалау буенча төбәкара конференция эшчәнлегендә республика һәм төбәкара гомуми белем бирү учреждениеләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары һәм иҗади эш белән катнашучы 7-11 сыйныф укучылары.

## II. Конференциянең максат һәм бурычлары

Конференция Туфан Габдулла улы Миңнуллинның иҗади мирасын киңрәк өйрәнү һәм популярлаштыру максатыннан үткәрелә.

**Конференциянең бурычлары:**

- Туфан Миңнуллинның иҗади мирасы белән тирәнтен танышу;
- Татар әдәбиятын, мәдәниятен һәм сәнгатен өйрәнү һәм популярлаштыру;
- Яшь буында толерантлык, патриотизм хисләре тәрбияләү һәм үстерү;
- Иҗади эшләүче укытучыларны барлау, аларның педагогик эшчәнлеген активлаштыру;
- Сәләтле балаларны ачыклау һәм аларның иҗади үсеше өчен шартлар тудыру.

## III. Конференцияне оештыручылар

- Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитеты Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе;
- Яр Чаллы шәһәре мәгълүмати-методик үзәге;
- Яр Чаллы шәһәре язучылар берлеге;
- Яр Чаллы шәһәре педагогик университеты;
- Яр Чаллы шәһәре МБГББУ “29 нчы гимназия”.

## IV. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

## IV. Конференцияне оештыру һәм үткәрү тәртибе

Конференция 2019 нчы елның 19 нчы мартында Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәренең 29 нчы гимназиясендә уздырыла (Адрес: Яр Чаллы шәһәре, Яшь ленинчылар бульвары, 3 нче йорт, 27/21).

*1. Конференция ике турда үтә:*

**1 нче тур -** 2019 нчы елның 1 нче мартыннан 10 нчы мартына кадәр фәнни-гамәли конференциядә катнашу өчен гаризалар, укучыларның иҗади эшләре, укытучыларның хезмәтләре һәм чыгыш тезисларының электрон вариантлары Яр Чаллы шәһәре 29 нчы гимназиянең электрон адресына gim29_chelny@mail.ru кабул ителә. Килгән эшләр махсус комиссия - Эксперт советы тарафыннан анализлана, кабул ителгән критерийлар нигезендә бәяләнә. Нәтиҗәләр 10 нчы мартка кадәр, комиссия тарафыннан тикшерелеп, 29 нчы гимназия сайтына https://edu.tatar.ru/n_chelny/sch28/gym29 урнаштырылачак. Икенче турда катнашырга чакыру хатлары 2019 нчы елның 17 нче мартына кадәр җибәрелә.

**2 нче тур -** 1 нче турда югары балл җыйган хезмәт авторлары 2019 нчы елның 19 нчы мартына регионара фәнни-гамәли конференциянең финалына чакырыла.

Конференциядә чыгыш ясау өчен 5 минут, дискуссияләр өчен 5 минут вакыт бирелә. Шул вакыт эчендә катнашучы төп фикерләрне кыска һәм төгәл итеп җиткерә белергә тиеш.

*2. Конференциядә катнашучылар:*

1. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары;
2. Гомуми белем бирү оешмаларының, гимназия, лицейларның 7-11 нче сыйныф укучылары.

*3. Укытучыларга эзләнү эшләре түбәндәге юнәлешләрдә тәкъдим ителә:*

1. Туфан Миңнуллинның иҗтимагый эшчәнлеге һәм публицистикасы (эзләнү эше шагыйрь иҗатының үзенчәлекле якларын, иҗтимагый эшчәнлеге һәм публицистик эшчәнлеген яктыртырга, Туфан Миңнуллинны якыннан белгән, аралашкан кешеләрнең истәлекләренә, архив материалларына нигезләнгән булырга мөмкин).

2. Туфан исемен мәңгеләштерү (Туфан Миңнуллинның музейларын барлау, аларның ачылу тарихын ачыклау, Туфан исеме кайда, нәрсәләргә бирелгән; аларны барлау, анализлау характерында булырга мөмкин).

3. Туфан Миңнуллин иҗатында милләт язмышы (язучының бу темага язылган әсәрләренә анализ, теманың бүгенге көндә актуальлеген ачыклау характерында булырга мөмкин).

4. Иҗади эш. Журналистика. «Кызыл тышлы дәфтәрдән».

Журналистик язмаларның (мәкалә, интервью, репортаж, хат һ.б.) тематикасы:

1. «Татар кешесе! Бел! Син сөйләшкән тел, дистәләгән гасырлар буенча чарланып, иң камил телләр дәрәҗәсенә күтәрелгән... Аны хөрмәт ит, сакла һәм үстер!» (Т.Миңнуллин. Татарның әхлакый кодексы).

2. «Җиңелүләр дә җиңүгә илтә ала». (Т.Миңнуллин)

Журналистик язмаларның күләме Times New Roman, 14 кегель, 1,5 интервал белән 5-7 биттән артмаска тиеш.

*4. Укучыларга иҗади эшләр түбәндәге юнәлешләрдә тәкъдим ителә*

1. Туфан Миңнуллин иҗатында милләт язмышы (Язучының бу темага язылган әсәрләренә анализ, теманың бүгенге көндә актуальлеген ачыклау характерында булырга мөмкин).

Тематика:

— Т.Миңнуллин иҗатында халыкның гореф-гадәтләре, йолалары чагылышы;

— Т.Миңнуллин иҗатында татар милли характеры гәүдәләнеше;

— Драматург иҗатында халыкның төрле милли-этник катламнары (керәшеннәр, мишәрләр һ.б.) тормышы чагылышы;

**V. Фәнни- тикшеренү эшенең эчтәлегенә һәм калыбына таләпләр**

Фәнни- тикшеренү эшенең структурасы

Фәнни эш кабул ителгән стандарт кысаларында билгеле бер структурага нигезләнеп үтәлә. Титул бите, эчтәлек, кереш, төп, йомгаклау өлешләре, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымта өлешләреннән тора. Кереш өлештә эзләнүнең максат-бурычлары, предметы, кулланылган методлар, нәтиҗәләр күрсәтелә. Төп өлештә теманың гамәли әһәмияте өйрәнелә.

Эшләр татар телендә кабул ителә. Хезмәтнең тексты компьютерда җыелган булырга тиеш. Күләме 8-10 бит. Эзләнү эшендә күрсәтмә материаллар (рәсем, схема һәм карта, таблица, фоторәсемнәр, архив материаллары булырга мөмкин, күләме 5 бит). Шрифт Times New Roman- 14; полялар: сулдан 30мм, уңнан 15 мм, астан һәм өстән 20мм. Юл араларында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1см калдырып башлана.

Тезисларны тәкъдим итү тәртибе:

- тезислар Word редакторында А4 форматында 1 интервал белән җыелырга тиеш. (Шулай ук zip-, rar- архивлаштыру форматын кулланырга мөмкин) Шрифт Times New Roman-14; өстән, астан, уңнан, сулдан полялар 2,5см. Полялар рамка эченә алынмый.
- фәнни-эзләнү эшенең төп фикерләрен кыскача чагылдырырга тиеш;
- тишерелгән, төзәтүләрсез була;
- исеме уртага 14 нче шрифтны калынайтып языла, ахырда нокта куелмый;
- авторның исеме, фамилиясе тулаем күрсәтелә, мәктәбе 14 нче шрифт белән битнең уң як өлешенә языла;
- яңа юлдан башланучы фразалар кызыл юлдан 1,27 см калдырып башлана;
- тезислар күләме 1,5 биттән артмаска тиеш;

Таләпләргә туры килмәгән хезмәтләр тикшерелми.

**VI. Бәяләү критерийлары**

Татарстан язучылар берелегенең Чаллы бүлеге шагыйрьләре, язучылары; Яр Чаллы шәһәренең Мәгариф һәм яшьләр белән эшләү идарәсе белгечләре; Яр Чаллы дәүләт педагогия университеты галимнәре; Яр Чаллы шәһәренең югары квалификацион категорияле укытучыларыннан торган экспертлар комиссиясе укытучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына түбәндәге критерийлардан чыгып бәя бирә:

**чыгышлар яттан яки өлешчә яттан сөйләнергә тиеш:**

- ✓ билгеле булган фәнни фактларны куллану;
- ✓ сөйләмнең аңлаешлы булуы, кыскалык һәм ачыклык, күргәзмәлелек;
- ✓ аудитория белән элемтә;

- ✓ оригинальлек, заманчалык һәм чыгыш барышында цифрлы белем бирү ресурсларын нәтиҗәле куллану;
- ✓ чыгышны күрсәтмә материаллар (рәсем, фоторәсемнәр, презентация) белән баету.

**Оештыручылар эшләрне түбәндәге очракта кире кага ала:**

- ✓ авторлык буенча шикләр уянса;
- ✓ күрсәтелгән вакыттан соңрак тапшырылса;
- ✓ РФ һәм ТР кануннарына каршы килсә;
- ✓ конференциянең тематикасына туры килмәсә;
- ✓ бизәлеш тәртипләрен үтәмичә башкарылган булса;
- ✓ логик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион хаталар булса.

## VII. Йомгаклау

Укытучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына эксперт комиссиясе югарыдагы критерийлардан чыгып бәя бирә. Чыгышлар тыңланып беткәннән соң, һәр секциядәге экспертлар комиссиясе нәтиҗә чыгара. Карарлар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

Төбәкара фәнни-гамәли конференциядә катнашучыларга сертификатлар тапшырыла. Җиңүчеләргә дипломнар тапшырыла.

**Искәрмә:** һәр дәрәҗәдәге диплом берничә дә була ала.

Конференция нәтиҗәләреннән чыгып, резолюция кабул ителә.

Элемтә өчен:
29 нчы гимназия – 8(8552) 54-38-27,
89625680540 - Фарваева Илсөяр Илшат кызы
89172243068 - Исхакова Рима Мөхәррәм кызы
89376003400 – Галиева Зәлифә Габбас кызы
Электрон почта: gim29_chelny@mail.ru

*Кушымта 1*

Туфан Миңнуллин исемендәге
укытучыларның һәм укучыларның регионара конференциясендә катнашу өчен

Гариза (укучылар өчен)

| № | Ф.И.О., сыйныфы | Автор укыган белем бирү оешмасының тулы исеме | Фәнни яки иҗади юнәлеш номинациясе, эшнең исеме, күләме | Авторның почта буенча тулы адресы, электрон адресы, телефоны | Җитәкченең Ф.И.О.; предметы, телефоны, электрон адресы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

Гариза (укытучылар өчен)

| № | Ф.И.О. | Автор эшләгән белем бирү оешмасының тулы исеме | Фәнни яки иҗади юнәлеш номинациясе, эшнең исеме, күләме | Авторның почта буенча тулы адресы, электрон адресы, телефоны |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

*Кушымта 2*
*Титул бите*

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ УКЫТУЧЫЛАРНЫҢ ҺӘМ УКУЧЫЛАРНЫҢ ТӨБӘКАРА КОНФЕРЕНЦИЯСЕ**

Иҗади эш. Журналистика. «Кызыл тышлы дәфтәрдән».

**ТУФАН МИҢНУЛЛИН ЯРАТКАН ШӨГЫЛЕ**

**Яр Чаллы шәһәре,**
**МБГББУ “29нчы гимназия”**
**8нче сыйныф**
**Сафина Айсылу**

Җитәкче: Галимова Әнисә Әхмәт кызы,татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

Яр Чаллы
2019

*Кушымта 3*

Согласие на обработку персональных данных

Я, ______________________________________________________________________,

(ФИО родителя или законного представителя)

паспорт _____ ____________,
выдан_______________________________________________

(серия, номер) (когда, кем)

_______________ ____________________________________________________________

(в случае опекунства / попечительства указать реквизиты документа, на основании которого осуществляется опека или попечительство)

____________________________________________________________________________

(адрес)

даю согласие на обработку персональных данных моего ребенка

____________________________________________________________________________

(фамилия, имя, отчество ребенка)

паспорт _____ _____________, выдан ____________________________________________

(серия, номер) (когда, кем)

____________________________________________________________________________

____________________________________________________________________________

(адрес)